Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2023 елның 05 июле №16

Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит авылында «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Янил авыл җирлеге Уставы нигезендә, Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елның 16 июленә 14 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вахит авылы, Яшьләр урамы адресындагы Сабантуй уздыру урынында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:«Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлегенең Вахит торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 25 ноябрендәге 1 номерлы Вахит авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә Сез ризамы:

2.1. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чишмәләргә йортлар (будкалар) урнаштыру, төзекләндерү һәм ремонтлау, чишмәгә керү юлларына, парковкаларга вак ташлар салу, асфальтлау, яктырту җайланмалары, смета документларын төзү»

2.2. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«парк һәм аның тирәсендәге территорияне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, арт-объектлар һәм МАФлар (кече архитектура формалары) сатып алу һәм урнаштыру, парк һәм ял зоналары өчен эскәмияләр ясау, сатып алу һәм урнаштыру, смета документларын төзү»

2.3. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - канализация челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, модернизацияләү, смета документларын төзү»

2.4. 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - физик культура һәм спортны үстерү, спорт инструкторларына түләү, спорт инвентаре сатып алу, спорт мәйданчыкларын карап тоту һәм төзекләндерү, смета документларын төзү»

2.5. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « - Вахит авылында тукталыш павильоны урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, смета документларын төзү»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Янил авыл җирлеге башлыгы: И.Х. Корбанов.